A. T. S. S. C. Qazan LENIN ...

ПӘНҖЕШӘМБЕ
15 МАРТ
1940 ел
№ 62 (5862)
Аерым номеры 10 тиен

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) Өлкә Комитеты, Шәһәр Комитеты, ТАССР Верховный Советы һәм Шәһәр Советы органы.

РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ: Казан, Матбугат йорты. ТЕЛЕФОННАР: экономик бүлек 18—22, авыл хуҗалыгы һәм совет төзелеше бүлекләре 4—58, партия бүлеге һәм матбугат күзәтү бүлеге 14—75, хатлар бүлеге 21—28, культура бүлеге 18—22, информация бүлеге 5—86, тенге редакция 3—75, типография 36—60, бухгалтерия һәм игланнар бүлеге 2—19.

Совет законнарын тайпылышсыз үтәү өчен

Кешелек тарихында яңа эраны ачкан Бөек Октябрь Социалистик революциясе җир шарының алтыдан бер өлешендә эксплоататор сыйныфларны власть башыннан бәреп төшерде, аларның дәүләт аппаратын, шул исәптән суд системасын һәм законнарын юкка чыгарды һәм пролетариат диктатурасын урнаштырды. Революция утында яңа власть—чын халык власте, яңа суд—чын халык суды, яңа хокук һәм законлылык—социалистик хокук һәм законлылык туды һәм аларның чәчәк атуы өчен чикләнмәгән мөмкинлекләр тудырылды.

Сталин Конституциясе һәм аның нигезендә төзелгән „ССР Союзының, Союзный һәм автономияле республикаларның суд төзелеше турында закон“ совет судын, дәүләт властеның барлык органнары кебек үк, демократизмның яңа, югары баскычына күтәрде.

Эксплоататор сыйныфларның судыннан үзенең максаты һәм бурычлары буенча принципиаль рәвештә аерылып торган совет суды безнең илебездә социалистик гадел хөкемне тайпылышсыз рәвештә тормышка ашыруга чакырылган. Пролетариат диктатурасы тудырган безнең законнарыбыз социалистик строеның, социалистик хуҗалык системасын, социалистик милекне, социалистик дәүләт һәм халык интересларын саклауга юнәлдерелгән. Алар, совет законнары, социалистик төзелешнең барлык этапларында, эчке һәм тышкы дошманнарга, буржуазиянең троцкийчы-бухаринчы һәм буржуаз милләтче агентларына каршы көрәштә һәм аларны тар-мар итүдә, һәр төрле җинаятьчеләргә каршы көрәштә, экономикада гына түгел, бәлки кешеләрнең аңында да капитализм калдыкларын бетерү өчен көрәштә ирешелгән уңышларыбызны яулап алуда бәя биреп җиткерә алмаслык зур роль уйнадылар.

Хәзер, илебез үсешенең яңа полосасында, хезмәт ияләренә коммунистик тәрбия бирү эше, кешеләрнең—коммунизм төзүчеләрнең аңында капитализм калдыкларын бетерү хәл иткеч әһәмият алган вакытта, законнарның тоткан урны аеруча зур. Һәм шуңа күрә дә „...законнарның стабильлеге хәзер безгә кайчан гына булганга караганда да артыграк кирәк“. (Сталин).

Совет гадел хөкеменең иң әһәмиятле бурычларыннан берсе совет законнарының барлык учреждениеләр, оешмалар, хезмәттәге кешеләр һәм гражданнар тарафыннан дөрес һәм тайпылышсыз үтәлүен тәэмин итүдән гыйбарәт. Совет суды законнарның дөрес һәм тайпылышсыз үтәлүен тәэмин итәргә, аларның стабильлеге принципына каршы килә торган күренешләргә, законнарны бозуга юнәлдерелгән һәр төрле маташуларга каршы аяусыз көрәш алып барырга тиеш.

Суд органнары, шул исәптән республикабызның суд органнары, Сталин Конституциясе һәм суд төзелеше турындагы яңа закон белән коралланганнары хәлдә, үзләренең эшен яңа обстановкада яңача яңгыраган бурычларга туры китереп үзгәртеп коруда шактый уңышларга ирештеләр. Суд эшенә Ленин—Сталин партиясенә ахрынача бирелгән яңа кадрлар күтәрелделәр, гадел хөкемне тормышка ашыруга хезмәт ияләренең яңа катлаулары тартылды. Суд органнарының эш практикасында булган күп сандагы җитешсезлекләрне, шул исәптән һәм бигрәк тә, судларга кергән эшләрне карауда булган волокитаны бетерүдә сизелерлек адым ясалды. Республикабыздагы халык судьяләренең күпчелеге халык судларының эше турында масса алдында регуляр рәвештә отчет бирә башладылар. Судларның халык белән элемтәсе тагын да ныгыды.

Бу уңышлар, әлбәттә, суд органнары работникларына тынычланырга һич тә хокук бирмиләр, киресенчә, совет законнарын дөрес һәм тайпылышсыз рәвештә тормышка ашыру буенча эшне кискен рәвештә яхшырту кирәклеген күрсәтәләр.

Большевистик турылык белән әйтергә кирәк, законнарны куллану өлкәсендә безнең күп кенә оешмаларыбызның һәм работникларыбызның, шул исәптән законнарны саклауда торучы суд һәм прокуратура работникларының да эш практикасында җитди кимчелекләр аз түгел әле. Фактлар эзләп еракка китәргә кирәкми, Яңа Чишмә, Юдино һәм башка кайбер районнарның халык судларының, ТАССР Верховный Судының, аерым алганда аның уголовный һәм гражданский эшләр буенча суд коллегияләренең эш практикасын алу да җитә. Бу районнарның халык судлары кирәк уголовный, кирәк гражданский эшләрне карауда булсын, җитди ялгышларга юл куялар, еш кына законга нигезләнмәгән карарлар һәм приговорлар чыгаралар. Шулай итеп, аларның эш практикасында материаль һәм процессуаль законнар тупас рәвештә бозыла.

Верховный Судның суд коллегияләре халык судьяләрен эшкә конкрет мисальләрдә һәм фактларда өйрәтәсе һәм шуның белән аларга булышлык күрсәтәсе урынга, күп кенә хәлләрдә эшләр буенча ялгыш определениеләр чыгарып, аларга дөрес булмаган ориентация бирәләр.

Республиканың кайбер суд органнары эшендә булган зур җитешсезлекләрнең берсе җәзалау политикасын үткәрүдә булган бозылардан гыйбарәт. Кайбер халык судларының эш практикасында җинаятьләргә дөрес бәя бирелми, суд җаваплылыгына нигезсез тартуларга юл куела. Шул ук вакытта совет законнарының бөтен катылыгы белән җәзаланырга тиешле элементларга—һәр төрле спекулянтларга, хулиганнарга, растратчикларга, социалистик милекне урлаучыларга һәм башка шундый җинаятьчеләргә карата җәзалау политикасы җитәрлек кулланылмый, йомшак приговорлар чыгарыла. Нәтиҗәдә, алар җаваплылыктан читтә калалар. Бу хәлне һич тә нормаль дип санап булмый. Җәзалау политикасын үткәрүдә булган мондый кимчелекләр кичекмәстән бетерелергә тиеш.

Революцион законлылык өчен, совет законнарының тегәл һәм тайпылышсыз тормышка үткәрелүе өчен көрәш властьның барлык органнарының, партиянең барлык оешмаларының беренче чираттагы бурычы булып тора. Законнарны аз гына бозулар да җентекләп тикшерелергә, ә гаепле кешеләр каты җавапка тартылырга тиешләр. Суд һәм прокуратура органнары безнең илебездә социалистик стройны тагын да ныгытуга, коммунизмның тулы тантанасын яулап алуга юнәлдерелгән совет законнарының дөрес үтәлүен һич сүзсез тәэмин итәргә тиешләр.

Совет законнары—нык һәм какшамаслык! Аларны тайпылышсыз үтәү—ул, һәрбер совет гражданының изге бурычы.

Тынычлык политикасының яңа тантанасы

Хезмәт ияләре депутатларының Казан Шәһәр Советы Башкарма Комитеты работникларының митингысы булып үтте. Митингта катнашучылар СССР белән Финляндия арасында төзелгән солых договорын зур канәгатьләнү белән каршыладылар.

Митингта кабул ителгән резолюциядә түбәндәгечә әйтелә:

— Без, Казан Шәһәр Советы Башкарма Комитеты работниклары, СССР белән Финляндия арасында солых договорын тирән канәгатьләнү белән каршылыйбыз.

Бары тик Сталинчы политиканың [illegible] Финляндия белән мондый договорны төзи алдык. Сугыш уты кабызучылар тагын бер тапкыр җимергеч удар алдылар.

Шәһәр Советы Башкарма Комитеты работниклары бөек юлбашчыбыз иптәш Сталинның бөтен халыкларны мобилизацион хәзерлектә тотарга кирәклек турындагы күрсәтмәсен бер генә минутка да онытмыйлар. [illegible]

ЛЕНИНГРАД ХӘРБИ ОКРУГЫ ШТАБЫННАН ОПЕРАТИВ СВОДКАСЫ

13 нче мартта иртән 7 сәгатьтә безнең гаскәрләр 2 сәгатьлек штурмнан соң Выборг шәһәрен алдылар.

Фронтның башка участокларында көндезге 12 сәгатькә кадәр әһәмиятле бер нәрсә дә булмады.

Ленинград вакыты белән 12 сәгатьтә солых договоры туры китереп фронтның барлык участокларында сугыш хәрәкәте туктатылды.

ВКП(б) ның Татарстан оешмасының XXI нче Өлкә конференциясе

КОНФЕРЕНЦИЯНЕҢ МАНДАТ КОМИССИЯСЕ ДОКЛАДЫННАН

(ДОКЛАДЧЫ ИПТӘШ Г. П. ТИХОНОВ)

Партиянең XXI нче өлкә конференциясенә делегатлар партиянең шәһәр һәм район конференцияләрендә, шулай ук партия оешмалары аз булган районнарда—партиянең район җыелышларында сайландылар.

Түбәндәге чагыштырма саннарны күрсәтеп үтәргә кирәк: ВКП(б) ның XIX нчы өлкә конференциясенә делегатлар партиянең 12 оешмасында гына конференциядә сайланган булса, XXI нче өлкә конференциясенә партиянең 57 оешмасындагы конференцияләрдә сайландылар. Партиянең аз санлы оешмалары исәбенә авыллардагы оешмалар керүне күздә тотсак, отчет чоры эчендә һәм бигрәк тә ВКП(б) ның XVIII нче съездыннан соң алар иң яхшы кешеләр—колхоз производствосының һәм авыл интеллигенциясенең алдынгылары исәбенә үскәннәр дигән нәтиҗәне ясарга мөмкин.

Мандат комиссиясе партиянең XXI нче өлкә конференциясенә сайланган һәрбер делегатның полномочиесен тикшерде. Шушы тикшерү нәтиҗәсендә комиссия партиянең барлык оешмаларында сайлаулар дөрес үткәрелгәнлеген, барлык делегатлар да тавышларның кирәкле күпчелеген алганлыкларын билгеләде.

Мандат комиссиясе түбәндәгене әйтеп үтәргә кирәк дип саный: партиянең барлык конференцияләрендә делегатлар сайлау [illegible]

Сайлаулар партия сафларының гадәттән тыш берләшкән, партиянең Татарстан оешмасының Ленинче—Сталинчы Үзәк Комитеты тирәсенә, партиянең һәм халыкларның бөек юлбашчысы иптәш Сталин тирәсенә нык тупланганлыгын күрсәттеләр. (Алкышлар).

ВКП(б) ның Татарстан оешмасының XXI нче өлкә конференциясенә тавыш бирү хокукы белән барлыгы 367 делегат сайланган. Партия конференциясендә тавыш бирү хокукы белән 364 делегат катнаша. 3 делегат урынлы сәбәпләр буенча килмәгән.

Киңәш бирү хокукы белән партия конференциясендә 130 делегат катнаша, шулардан 22 делегат ВКП(б) Өлкә Комитеты пленумының һәм ревкомиссиясенең членнары һәм кандидатлары.

Партиянең Казан шәһәр оешмасы иң күп делегация җибәргән оешма булып тора. Бу оешма тавыш бирү хокукы белән 145 делегат сайлаган. Бу—партия конференциясенә тавыш бирү хокукы белән катнаша торган делегатларның гомуми санына карата 39,5 процент.

Зеленодольски шәһәр оешмасыннан, Юдино һәм Чистай шәһәр оешмаларыннан тавыш бирү хокукы белән тугызар, Бөгелмә оешмасыннан тавыш бирү хокукы белән 7 делегат сайланган. Башка партоешмалардан тавыш бирү хокукы белән азрак делегат сайланган.

Шуны әйтеп үтәргә кирәк: әгәр үзләренең көндәлек эшләрендә партия кандидатларын членлыкка вакытында кабул итү мәсьәләсенә күбрәк игътибар биргән булсалар, партиянең кайбер оешмалары тавыш бирү хокукы белән

күбрәк делегат сайлый алган булырлар иде.

Мәсәлән, партиянең Казан шәһәр оешмасында кандидатлык срогы узган 1.200, Зеленодольски шәһәр оешмасында 100 дән артык, Чистай оешмасында—80 нән артык, Әгерҗе оешмасында — 75 кеше бар һ. б.

Партия кандидатларының членлыкка кабул итү буенча канәгатьләнмәслек эшләү нәтиҗәсендә, партия кандидатлары арасындагы күп санлы актив алдынгы кешеләр ВКП(б) ның XXI нче өлкә конференциясенә сайлауларда партия членнары сыйфатында катнаша алмыйча калдылар.

Партиянең шушы конференциясенә җибәрелгән коммунистларның сан составы турында берничә сүз.

ВКП(б) ның Татарстан оешмасының XXI нче өлкә конференциясе алдыннан, дөресрәге 1940 елның 1 нче мартына партиянең Татарстан оешмасында 20.894 член һәм 14.887 кандидат бар. Партия конференциясенә партиянең барлык районнардагы оешмаларыннан вәкилләр сайланды.

ВКП(б) ның Татарстан оешмасының XIX нчы конференциясе белән XXI нче конференциясе арасындагы чорда, административ-территориаль оешмаларны ваклау нәтиҗәсендә, партиянең район оешмаларының саны 66 дан 69 га кадәр үсте. Шул ук вакыт эчендә 814 башлангыч партоешма төзелде, шулардан Казан шәһәрендә—102 оешма, авыл районнарында—706 оешма һәм Зеленый Долда—6 оешма.

Конференциядә тавыш бирү хокукы белән катнашучы делегатларның составы түбәндәгечә: 155 кеше партия органнарында эшләүчеләр. Шулар эченнән 24 кеше башлангыч партоешма секретарьлары. Делегатлар арасында промышленность һәм транспорт работниклары 39 кеше, колхоз, совхоз, МТС ларда эшләүче работниклар—29 кеше, культура, фән һәм сәнгать работниклары—24 кеше.

Тавыш бирү хокукы белән катнашучы делегатларның составы белемнәре ягыннан түбәндәгечә:

Югары белемлеләр—12,67 процент, тәгәлләнмәгән югары белемлеләр—1,65 процент, урта белемлеләр—36,36 процент, башлангыч белемлеләр—49,32 процент.

Бу коференциядәге делегатлар составының гомуми культура дәрәҗәсе XIX нчы конференция составына караганда югарырак. Бу—партиянең Татарстан оешмасы членнарының культура дәрәҗәсенең гомуми үсешен күрсәтә.

Тавыш бирү хокукы белән катнашучы делегатлар составы партия стажлары ягыннан түбәндәгечә:

1917 нче елдан—7 кеше, 1918 нче елдан 3, 1919 нчы елдан 11, 1920 нче елдан—7, 1921 нче елдан 1924 нче елга кадәр—15, 1925 нче елдан 1930 нчы елга кадәр 187, 1931—1933—97, 1937—1940 елга кадәр—37 кеше.

Делегатлар арасында партиянең XIX нчы конференциясе белән XXI нче конференциясе арасындагы чорда түбәнге эштән җитәкче эшкә күтәрелгән күп кенә иптәшләр бар. Партия конференциясе делегатлары составында мондый иптәшләр 100 кеше, конференция эшендә беренче тапкыр катнашучылар—169 кеше. Бу—яңа кадрларны күтәрүнең гомуми процессын күрсәтә. Яшьләре буенча делегатлар составы түбәндәге саннар белән характерлана:

25 тән 30 яшькә кадәр—35, 31 дән—35 кә—142, 36 дан 40 ка—118, 41 дән 50 гә—63, 51 дән башлап һәм аннан югарылары 6 кеше.

Делегатларның милли составы турында. Партконференциянең эшендә 11 милләт делегатлары—руслар, татарлар, украинлылар, чувашлар, мордвалар, еврейләр, белоруслар, удмуртлар, башкыртлар, болгарлар һәм греклар катнашалар.

Руслар—175, татарлар—152 кеше. Бу, Ватаныбыздагы халыкларның җимерелмәслек нык дуслыгын, Ленин—Сталин милли политикасының тулы тантанасын тагын һәм тагын бер тапкыр күрсәтә.

Делегат хатын-кызлар турында аеруча әйтергә кирәк. Делегатлар составында тавыш бирү хокукы белән катнашучы хатын-кызлар 37 кеше яисә 10 процент, XIX нчы партконференциядә делегат хатын-кызлар 54 кеше, яисә 12,32 процент иде. Моннан партиябезнең күп кенә оешмалары хатын-кызларның үсүенә йомшак булышлык итәләр һәм аларны җитәкче партия, совет һәм хуҗалык постларына кыю рәвештә күтәрмиләр дигән нәтиҗәне ясарга мөмкин.

Партия конференциясендә киңәш бирү хокукы белән, югарыда күрсәтелгәнчә, барлыгы 130 делегат катнаша. Алар арасында: югары белемлеләр—21, урта белемлеләр—39, түбән белемлеләр—68 һәм аз белемлеләр (Кызыл Юл һәм Казан шәһәр партоешмаларыннан)—2 кеше.

Киңәш бирү хокукы булган делегатлар арасында хатын-кызлар 21 кеше. Тагын түбәндәге саннарны китерертә кирәк: делегатлар арасында СССР Верховный Советы депутатлары 8, РСФСР Верховный Советы депутатлары 14, ТАССР Верховный Советы депутатлары 44, Шәһәр Советы һәм район Советы депутатлары 241 кеше.

Орденнар һәм медальләр белән бүләкләнүчеләр 21 кеше.

Партиянең Татарстан оешмасының XIX нчы конференциясеннән бирле партиянең Татарстан оешмасы тагын да ныгыды. Коммунистлар ВКП(б) ның Татарстан оешмасының XXI нче өлкә конференциясенә партиябезнең төп юлы өчен иң актив көрәшкән кешеләрне сайладылар.

Партиянең Татарстан оешмасы әлегә кадәр булганнан да бердәмрәк һәм тупланганрак, ул сәламәт һәм көрәшкә сәләтле һәм бу аның уңышлы рәвештә алга баруының ышанычлы залогы.

Безнең алда хәл ителмәгән күп кенә бурычлар тора әле. Без аларны үтәрбез, чөнки безгә миллионнарча кешеләрне туплаучы, коммунизмның тантанасы өчен көрәшкә чакыручы байрак—бөек Сталин җитәкчелек итә! (Алкышлар).

КОНФЕРЕНЦИЯ КӨНДӘЛЕГЕ

Конференциянең 14 нче марттагы утырышында ВКП(б) Өлкә Комитетының һәм Ревизия Комиссиясенең докладлары буенча сөйләүләр дәвам итте. Делегатлар үзләренең чыгышларында партиянең Татарстан оешмасы ирешкән уңышларны, XVIII нче съезд карарларын һәм иптәш Сталин күрсәтмәләрен үтәү өчен барган көрәшнең нәтиҗәләрен конкрет саннар һәм фактлар белән күрсәтеп үттеләр.

Шуның белән бергә, ВКП(б) Өлкә Комитетының практик эшендә зур гына кимчелекләр дә яшәп килгән һәм аерым хәлләрдә кайбер ялгышлар да җибәрелгән.

— Өлкә Комитетының эшендә төп кимчелекләрнең берсе,—ди ВКП(б) Өлкә Комитеты секретаре иптәш **Матвеев**—ул, үтәлүне тикшерү эшләрен ныклап оештырмауда. Өлкә Комитеты аерым мәсьәләләргә карата бик яхшы карарлар чыгарды, ләкин ул карарларның үтәлешен системалы рәвештә тикшереп тормады. Шуның нәтиҗәсендә карарларның бер өлеше үтәлмичә калды.

Аннан соң иптәш Матвеев авыл хуҗалыгы өлкәсендә булган җитешсезлекләргә тукталып үтә һәм аларны бетерү юлларын күрсәтә. Хәзерге вакытта партиянең авыл райкомнарының төп бурычлары язгы чәчүгә үрнәк рәвештә хәзерләнүдән, югары уңыш өчен көрәшне большевикларча оештырудан гыйбарәт булуын әйтә.

ВКП(б) ның Чистай райкомы секретаре иптәш **Воробьев** үзенең чыгышында Татнаркомзем җитәкчеләрен каты тәнкыйть итә. Ул болай ди:

— Соңгы ике елда Татарстанда иген уңышының кимүен нәрсә белән аңлатырга? Моны, иң беренче чиратта, агротехниканы тормышка ашыруның начар булуы белән, авыл хуҗалыгында булган бай техникадан кирәгенчә файдаланмау белән, һәм, ниһаять, Актаныш МТС ы кебек алдынгы машина-трактор станцияләренең, шулай ук алдынгы стахановчыларның бай тәҗрибәләрен киң рәвештә популярлаштермау белән аңлатырга кирәк. Болар барсы да Татнаркомземның начар эшләвен, җир органнарына оператив җитәкчелек ителмәвен күрсәтәләр.

Партиянең Казан Шәһәр Комитеты секретаре иптәш **Бычков** промышленностьта күп станокчылар хәрәкәтенә җитәкчелек мәсьәләләренә һәм колхоз сәүдәсенең торышына туктала.

— Чыгып сөйләүче делегатлар күп мәсьәләләргә тукталдылар,—ди иптәш Бычков,—ләкин сөйләүчеләрнең берсе дә күп станокчылар хәрәкәте турында һәм колхоз сәүдәсенә җитәкчелек турында әйтмәделәр. Ә чынында исә бу эшләр бездә мактарлык тормыйлар. Шулай булгач аларны читләтеп үтәргә ярамый. Күп станокчылар хәрәкәтенә ВКП(б) Шәһәр Комитетының да, Өлкә Комитетының да җитәкчелек итүләре канәгатьләнерлек түгел. Колхоз сәүдәсе бөтенләй дип әйтерлек үз агымына куелган. Наркомторг бу мәсьәлә белән ныклап шөгыльләнми һәм колхоз сәүдәсен бүгенге сорауларга җавап бирерлек итеп оештырмый. Шәһәр хезмәт ияләрен авыл хуҗалыгы продуктлары белән тәэмин итү зур әһәмиятле эш һәм аны яхшы итеп оештыру өчен практик чаралар күрергә кирәк.

Татарстан Җир Эшләре Халык Комиссары иптәш **Черзор** Наркомзем эшендәге җитешсезлекләргә туктала һәм бу Наркоматка карата ясалган тәнкыйтьнең бик урынлы булуын белдерә. Аннан соң ВКП(б) Өлкә Комитетының һәм Татарстан Совнаркомының Наркомземга җитәкчелекләре турында сөйли. Татсовнарком Наркомзем тарафыннан куелган мәсьәләләрне үз вакытында хәл итмәгән һәм практик булышлык оештырмаган.

— Татарстан Совнаркомы үзенең эшендә төп буынны тотып ала белми, күбрәк агымдагы мәсьәләләр белән генә шөгыльләнә,—ди иптәш Черзор.

Аннан соң Борщев (Юдино районыннан), Хөсәенев (Бондюг заводыннан), Анушкин („Красная Татария“ газетасы редакторы), Контюков (Татарстан Мәгариф Халык Комиссары) иптәшләр чыгып сөйләделәр. Алар барсы да партиянең XVIII нче съезды карарларын үтәүнең торышына һәм алдагы бурычларга тукталып үттеләр. Шуның белән фикер алышулар тәмам була. Конференция утырышына председательлек итүче иптәш Динмөхәмәтов (Татарстан Верховный Советы Президиумы председателе) фикер алышуларны туктату турында делегатлар тарафыннан тәкъдим кергәнлекне белдерә һәм аны тавышка куя. Күпчелек делегатлар бу тәкъдимне яклап тавыш бирәләр һәм шуның белән фикер алышулар туктатыла.

ВКП(б) Өлкә Комитетының һәм Ревизия Комиссиясенең отчетлары буенча сөйләргә теләп барлыгы 126 кеше язылган иде. Шулардан 57 иптәш чыгып сөйләде. Аннан соң йомгаклау өчен иптәш Алемасовка сүз бирелде.

Иптәш Алемасов делегатлар тарафыннан язма рәвештә бирелгән сорауларга тулы җавап биргәннән соң, кыска речь сөйләде. Конференциядә фикер алышуларның идея-политик яктан югары дәрәҗәдә үтүен, делегатлар тарафыннан ясалган тәнкыйтьнең бик урынлы булуын әйтте. Партиянең Татарстан оешмасы алдында торган якындагы бурычларны билгеләп үтте. Иптәш Алемасовның партия эше өчен һәрбер коммунистта җаваплылык хисе күтәрелү турындагы, оешманың сугышчанлыгы тагын да үсү һәм ВКП(б) Үзәк Комитеты тирәсенә, бөек юлбашчыбыз иптәш Сталин тирәсенә тагын да тыгызрак тупланган булуы турындагы белдерүен делегатлар көчле кул чабулар белән каршы алдылар.

Иптәш Алемасовның йомгаклау сүзеннән соң мандат комиссиясе председателе иптәш Тихоновның доклады булды. Конференция, Ревизия Комиссиясенең һәм мандат комиссиясенең докладларын бер тавыштан раслады.

Конференция ВКП(б) Өлкә Комитетының политик линиясен дөрес һәм практик эшен канәгатьләнерлек дип тапты.

Бүгенге утырыш көндез сәгать 11 дә башлана.

ВКП(б) нын ТАТАРСТАН ОЕШМАСЫНЫҢ XXI нче ӨЛКӘ КОНФЕРЕНЦИЯСЕ

ВКП(б) ӨЛКӘ КОМИТЕТЫНЫҢ ҺӘМ РЕВИЗИЯ КОМИССИЯСЕНЕҢ ОТЧЕТЛАРЫ БУЕНЧА ФИКЕР АЛЫШУЛАР

Казан тимер юлын алдынгылар сафына чыгарыйк

Казан тимер юлының политбүлек начальнигы иптәш Мандур реченнән

Партия һәм Совет хөкүмәте тимер юл транспортының эшен тагын да яхшырту өчен, дәүләт тарафыннан бирелгән заданиеләрне төгәл үтәсен өчен бөтен чараларны күрәләр. Ләкин безнең

Казан тимер юлы әле һаман да начар эшләвендә дәвам итә. Казан тимер юлы йөк төяү һәм бушату планын үтәүдә артка калып килә.

Җитешсезлекләрнең берсе шуннан гыйбарәт ки, без тимер юлның эшенә дөрес анализ ясарга, СССР Юл Эшләре Халык Комиссары иптәш Л. М. Каганович тарафыннан, ВКП (б) Өлкә Комитеты тарафыннан күрсәтелә торган булышлыклардан тулы файдаланырга өйрәнмәдек әле.

Казан тимер юлы политбүлегенең эшендә төп җитешсезлек шунда ки, юл командованиесенең тынычлануга бирелүен белә торып, кайбер хәлләрдә шуна юл куеп килде. Тимер юл идарәсендәге һәм урыннардагы кайбер тынычланучы җитәкчеләрне вактында тәртипкә чакыра белмәде.

Казан тимер юлында тапшырылган эшнең үтәлешен тикшерү, системалы рәвештә контрольлек итү мәсьәләсе белән шөгылләнмиләр. Юл хуҗалыгын сәламәтләндерү турында ВКП(б) нын Татарстан Өлкә Комитеты карарын безнең партия оешмасы үтәмәде. Мин, политбүлек начальнигы буларак, бу әһәмиятле карарны үтәүне тәэмин итә алмадым.

1939 нчы елның 10 нчы ноябрендә ВКП (б) Өлкә Комитеты бу мәсьәләне янадан куярга һәм карар кабул итәргә мәҗбүр булды. Без ВКП (б) Өлкә Комитетының бу соңгы карарын үтәүдә шактый эшләр башкардык. Ләкин юл хуҗалыгын тәртипкә китерү өлкәсендә, без ул карарның тулы үтәлүен тәэмин итә алмадык әле. Безнең бурычыбыз юл хуҗалыгын сәламәтләндерү өчен үзебездә булган бөтен эчке ресурслардан чын магнәсе белән файдаланудан гыйбарәт.

ВКП (б) Өлкә Комитеты безнең эшебезгә булышты һәм булышып килә. Ләкин бу җитәрлек түгел. Үзләренең территорияләреннән тимер юл линиясе үтә торган районнарнын райком секретарьлары белән киңәшмә булды. Бу киңәшмәгә барлыгы 157 кеше катнашты. Ә ВКП (б) Өлкә Комитетыннан һәм Шәһәр Комитетыннан киңәшмәгә бер кеше дә катнашмады. Бу факт ВКП (б) Өлкә Комитетының булышлыгы җитәрлек булмауны күрсәтә.

Әлегә кадәр яшәп килгән җитешсезлекләрне бетерергә, Казан тимер юлын алдынгылар сафына чыгарырга кирәк. Безнең партоешма депо дистанцияләренең, юл хуҗалыгының һәм бөтен Казан тимер юлының эшен яхшырту буенча барлык чараларны күрергә тиеш.

Җитәкчелек стиле турында

ВКП(б) ның Куйбышев райкомы секретаре иптәш Вахрушев реченнән

Иптәшләр! Мин, партия сафларын үстерү мәсьәләсенә тукталырга телим. Докладчы иптәш Әлемасов партиянең Татарстан оешмасы отчет чорында шактый үскәнлеген әйтеп үтте. Ләкин бездә бу эш өлкәсендә кимче-

лекләр дә бар әле. Партия сафларын төп профессия һәм бигрәк тә хатын-кызлар исәбенә үстерү эше канәгатьләнерлек түгел. Хатын-кызлар исәбенә үсешнең аз булуын нәрсә белән аңлатырга соң? Моны мин, хатын-кызлар арасында политик-масса эшенең начар алып барылуыннан, аларны җәмәгать эшенә актив катнаштыруга җитәрлек әһәмият бирелмәүдән дип әйтер идем.

Бездә, шул исәптән Куйбышев район партоешмасында, партиягә кабул итү мәсьәләсендә индивидуаль сайлап алу принципларын бозу фактлары бар. Шуның нәтиҗәсендә аерым кандидатларны 3—4 ай үткәч партиядән чыгарырга туры килде. Киләчәктә ВКП(б) сафларына кабул иткәндә иптәш Сталинның күрсәтмәләрен тулы үтәүне истән чыгармаска кирәк.

Авыл хуҗалыгы эшләренә җитәкчелек турында. Докладчы 1939 нчы елгы авыл хуҗалыгы эшләренә йомгак ясаганда башка кайбер районнар белән бергә Куйбышев районын да артта баруы өчен нык тәнкыйть итте һәм бу бик дөрес. Куйбышев районының авыл хуҗалыгы өлкәсендә артта калуының төп сәбәбе район партоешмасының һәм активының үзендә. Бу районның партактивы бик күп сөйләргә ярата, ә практик эшкә килгәндә ансы аларга кагылмый булып чыга. Үтәлешне тикшерү булмаганлыктан яхшы гына карарлар үтәлми калалар. Шуның белән бергә оешмада партия-масса эше һәм коммунистлар арасында партдисциплина бик йомшак. Мәсәлән, Куйбышевский шәһәрендәге партоешмада учетта торучылардан 80 кеше партия җәзасы алган. Бу саннар партоешмада эшнең, беренче чиратта партдисциплинаның начар торышын ачык күрсәтәләр.

Артта калучы районнарга Өлкә Комитетының һәм Наркомземның үз вактында тиешле контрольне һәм ярдәмне күрсәтүе кирәк. Ә Өлкә Комитеттан оператив җитәкчелек урнына кәгаз җитәкчелек күбрәк дияр идем. Мамадыш районына 1939 нчы елда гына да авыл хуҗалыгы мәсьәләсе буенча Өлкә Комитет һәм Совнарком җитәкчеләренең имзалары белән 378 телеграмма килгән. Шуларның ким дигәндә яртысында: „бу мәсьәләне райком бюросында тикшерегез“ дип күрсәтелгән. Менә инде күз алдына китерегез,—әгәр телеграммаларның 50 процентын бюрода тикшерсән, шуңа гына 180 тапкыр утырыш ясарга кирәк. Җәй көне берьюлы 10 телеграмма килде, барсы да ашыгыч, кайсын беренче чиратта үтәргә? Нишләргә белми аптырашка калуың бер дә гаҗәп нәрсә түгел. Бу нишләп алай килеп чыга соң? Моның сере шунда: Наркомат үзенең эше бармавын сизә һәм эшне үзе башкара алмагач Өлкә Комитетка йөгерә. Обком секретареннан телеграммага кул куйдырып райком секретарена җибәрәләр, шуның белән җаваплылыкны үзләреннән алып райком секретарьларына ташларга тырышалар.

Аннары иптәш Әлемасов докладында, райком секретарьлары район советының башкарма комитеты председательләренең, райзо һәм МТС җитәкчеләренең функцияләрен үзләренә алалар, дип әйтте. Райком адресына телеграммалар бер-бер артлы явып торгач, шулай килеп чыга да ул. Телеграммада турыдан-туры райком секретарена кушылган була һәм нәтиҗәсен бик тиз хәбәр итәргә дип әйтелә. Шулай булгач, бу эшне үзеңә эшләргә туры килә. Үзеңнең дөрес эшләмәвеңне, ул эшнең башка оешма үтәргә тиеш икәнлегең сизәсең, шулай да, тизрәк үтәү өчен үзең башкарасың.

Менә болай тарткалауларны, җитәкчелек эшендәге мондый яраксыз практиканы бетерергә, райком секретарьларының эшенә тиешенчә оператив җитәкчелек итүне булдырырга кирәк.

Промфинпланны үтәү—мактаулы бурыч

Татарстан Финанс Халык Комиссары иптәш Шәрәфиев реченнән

Татарстан Халык Комиссарлары Советының эшендә һәм шулай ук Наркомфин эшендә зур гына җитешсезлекләр булды. Дәүләт заданиеләрен һәм промфинпланның үтәүдә дисциплинасызлык, җебегәнлек күрсәтүче кайбер хуҗалык оешмаларына һәм предприятиеләргә карата без тиешле чараларны күрмәдек.

Финанс дисциплинасын ныгыту, промфинпланны һәм бюджетны үтәү—ныклы закон. Ләкин бу тармакта әле күп кенә кимчелекләр бар. Без, Татарстан Финанс Халык Комиссариаты линиясе буенча, 1939 нчы елны 4.325 оешмага тикшерү үткәрдек. Тикшерү нәтиҗәсендә финанс дисциплинасын меңнән артык төрле бозулар барлыгы беленде. Кайбер хуҗалык органнары дәүләт планнарын үтәү үтисе урында, төрле махинацияләргә бирелделәр. Мәсәлән, Ит тресты җитәкчеләре капиталь төзелеш расходларын, кагыйдә буларак, Промбанк аркылы үткәрергә тиешләр иде. Алар бу расходларны Госбанк аркылы үткәрәләр һәм үзләренә ясалачак финанс контроленнән котылырга уйлыйлар.

2 нче тегү фабрикасы планнан тыш төрле капиталь эшләренә 180 мең сум акча тота. Ремонт эшләренә планнан тыш 113 мең сум расход ясый. Бу расходларның күп өлешен киң куллану товарлары җитештерү исәбенә күчергән булып, күз буяу юлына басалар. Фактта исә фабрика киң куллану товарлары эшләп чыгару буенча бер нәрсә дә эшләми.

„Спартак“ комбинатында хуҗасызлык нәтиҗәсендә тотылган расходлар тагын да зуррак. Договор шартларын бозулар буенча штрафлар һәм неустойкалар 420 мең сум, хезмәт хакын артык тоту 412 мең сум исәпләнә.

„Кызыл Шәрык“ заводының дебиторлык бурычы зур. Яисә „Строитель“ кирпеч комбинатын алып карыйк. Бу комбинат бер вакытта да үзенең планын үтәгәне юк. Үткән елны комбинат 1 миллион 147 мең сум зарар күрде. Бу зарарның 721 мең сумы начар сыйфатлы продукция эшләп чыгаруга туры килә. Комбинат үткән елны бер генә данә дә беренче сорт кирпеч бирмәде.

Җиңел Промышленность предприятиеләре продукциянең эшләнү бәясе буенча 414 мең сум, хезмәт хакы фонды буенча 2 миллион 146 мең сум артык расход тоттылар. Җирле Промышленность Халык Комиссариаты бу мәсьәләдә күзәтеп торудан уза алмады.

Дәүләт средстволарының урынлы тотылуы өчен көрәштә Госпланның роле аз күренә. Госпланның кайбер работниклары үзләрен бик зурга куялар. Ә фактта исә аларның эшләгән эшләре кечкенә булып чыга. Планлаштыру мәсьәләсе—бик җидди эш. Шулай булуга карамастан, Госпланда, еш кына хәлләрдә, бу эшкә өстән генә карала. Наркомхозда коммуналь хуҗалыгы буенча капиталь салымны 1939 нчы елгы 4 миллион 700 мең сум урынына бары 54 миллион сум итеп планлаштырдылар. Госплан исә бу



гадәттән тыш күпертелгән планның 20 миллион сумнан артыграгын кабул итә. Шуннан соң Татарстан Халык Комиссарлары Советы бу проектны раслый. Нәтиҗәдә нәрсә килеп чыкты соң? Проект реаль булмаган, күпертелгән өчен югары оешмалар тарафыннан расланмады.

Бюджет турында берничә сүз. Кайбер районнар бу тармакта йомшак эшлиләр әле. Норлат районы аеруча артка калып бара. Ул бюджеты бары 91 процентка гына үтәде. Столбище районы 93 процент, Тәтеш районы 96 процент кына үтәделәр. Бу районнарның партия оешмалары бюджет мәсьәләсенә игтибар бирел җиткермиләр.

Районнардагы предприятиеләрнең әһәмиятләре зур. Чистай, Бөгелмә, Алабуга, Чаллы һәм башка районнарда җирле предприятиеләрнең планнарын тикшермиләр, аларның продукция эшләп чыгаруларын өстеннән контрольлек итмиләр.

Дәүләт байлыгына, социалистик милеккә саклык белән карарга, хуҗасызлыкка, дисциплинасызлыкка каршы көрәшне көчәйтергә кирәк. Дәүләт заданиеләрен һәм промфинпланны үтәү—урыннардагы барлык оешмаларның мактаулы бурычлары.

Районнарга—конкрет җитәкчелек

ВКП(б) ның Алексеевский райкомы секретаре иптәш Васильев реченнән

Партиянең Алексеевский район оешмасы авыл хуҗалыгының алдынгылары, Ленин—Сталин партиясе эшенә чын күңелдән бирелгән кешеләр — стахановчылар, ударниклар хисабына отчет чорында 76 процент үсте. Алар арасында элекке шофер, хәзер механик итеп күтәрелгән Парамонов, шофер Шорин, Почет тактасына кертелгән һәм 1940 нчы елда Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсенә кандидат итеп расланган Кожевников һәм производствода гүзәл эш үрнәкләре күрсәтүче башка иптәшләр бар.

Отчет-сайлау җыелышлары һәм партиянең район конференциясе башлангыч партоешмаларның эшләрендәге һәм, бигрәк тә, ВКП(б) райкомының җитәкчелегендәге җидди җитешсезлекләрне ачтылар. Башлангыч партоешмалар төп профессия кешеләре хисабына бик йомшак үстеләр: ВКП(б) сафларына барлык алынучылар составында—тракторчылар бары тик 6 процент, комбайнчылар 2 процент. Алынучылар арасында хатын-кызлар барлыгы 18 процент. Безнең район партоешмасында кандидатлык сроклары үтеп киткән 41 кеше хисаплана.

„ВКП(б) тарихының кыскача курсы“ басылып чыгу уңае белән районда партия пропагандасы шактый яхшырды. Партия тарихын 328 кеше үзлегеннән өйрәнә, алар арасында—221 кеше ВКП(б) члены һәм кандидаты. Ләкин

биредә дә, билгеле, җитешсезлекләр бар—районның барлык җитәкче работниклары да ВКП(б) тарихын өйрәнәләр дип булмый әле, иптәшләрчә беседалар бик аз үткәрелделәр.

Алексеевский районының авыл хуҗалыгы эшләре буенча һәр ел саен артта калуы һәм хуҗалык-политик чаралары планының үтәлмәве турында ВКП(б) ның Өлкә Комитеты да, Татарстан Совнаркомы да күптән беләләр. Алексеевский районына ярдәм кирәк дип, 4 ел буе сөйләп киләләр инде, ләкин бу ярдәм һаман да күрсәтелгәне юк әле.

Безнең районда машина-трактор станцияләре начар эшлиләр. Ромодановский МТС ы, җиһазландырылган мастерское булмавы аркасында, аеруча артка кала. Совнарком һәм Наркомзем бу МТС та мастерской төзүне күптән планлаштырганнар иде, ләкин конкрет бер нәрсә дә эшләмәделәр. Клуб төзү турында Совнарком белән булган безнең сөйләшүләребез дә инде икенче елны дәвам итә.

Өлкә Комитеты инструкторларының эшләре турында берничә сүз. Менә аларның райкомнарга ничек „ярдәм“ итүләрен күрсәтә торган мисальләрнең берсе. 1939 нчы елның язында безгә ВКП(б) Өлкә Комитетының пропагандисты иптәш Гарифуллин махсус задание белән, бер колхозда пропаганда эшен оештыру заданиесе белән килде. Колхозда 3 көн булганнан соң, ул үзе күргән төрле кимчелекләр турында Өлкә Комитетка доклад запискасы язган, ләкин пропаганда турында бер сүз дә әйтмәгән.

Безгә, район работникларына, ВКП(б) Өлкә Комитетының кадрлар. бүлеге күп ярдәм итәргә тиеш. Ләкин биредә кешеләрне практик эштә түгел, ә, бәлки, анкеталар буенча гына өйрәнәләр. Мин бер генә мисаль китерергә уйлыйм. МТС директоры иптәш Королев бик начар эшли. Ләкин аны алмаштыру турында безнең таләпләребезгә, кадрлар бүлеге „без аны авырса гына алмаштыра алабыз, әгәр дә эшли алмаса—ярдәм итәргә кирәк“ дип җавап бирә. Минемчә, мондый практика дөрес түгел.

Авыл районнарына ныграк игтибар бирергә

ВКП(б) ның Тәкәнеш райкомы секретаре иптәш Искәндәрев реченнән

Партиянең Татарстан оешмасы отчет чорында шактый уңышларга ирешә һәм бу уңышлар отчет докладларында ачык күренде. Бу чорда ВКП(б) Өлкә Комитеты һәм аның бүлекләре тарафыннан бик күп эшләр башкарылды. Шул ук вакытта Өлкә Комитет бүлекләренең эшләрендә җидди кимчелекләр дә булды. Мин шулар турында, аерым алганда оештыру-инструкторлык бүлегенең һәм авыл хуҗалыгы бүлегенең кимчелекләре турында сөйләргә телим. Авыл районнарындагы оешмаларга оештыру-инструкторлык бүлеге инструкторларының булышлыклары җитәрлек булмады.

Бер вакыт безнең районга инструктор иптәш Габитов килгән иде. Райкомда ул дүрт көн буена эшләде. Ләкин райкомның оештыру-инструкторлык бүлеге мөдире белән беседа ясау өчен 15 минут кына булса да вакыт таба алмады. Бу инде Өлкә Комитет инструкторларының эшендәге бер яклылыкны күрсәтә. Алар үзләренә тапшырылган конкрет бер мәсьәлә белән мавыгып, шунда ук хәл итәргә кирәкле булган башка мәсьәләләргә игтибар итмиләр. Оештыру-инструкторлык бүлеге күп кенә мәсьәләләр буенча районнарга вактында җавап бирми. Бу аның эшендәге төп кимчелек. Мәсәлән, иптәш Шәйхеттинов 1939 нчы елның 3 нче октябрендә партиягә кире кайтарылган иде. Өлкә Комитетның бу турыдагы карарыннан күчермәне без берничә тапкырлар сорадык, ләкин оештыру-инструкторлык бүлеге аны вактында җибәрмәде. Бу карарны 1940 нчы елның 15 нче январенда Казанга килеп үземә эзләп алырга туры килде.

Өлкә Комитетның авыл хуҗалыгы бүлеге эшендә дә җидди кимчелекләр бар. Кай вакытларда бу бүлек ниндидер статистика учреждениесенә әйләнеп китә. Бер вакыт, мин ялда вакытта, авыл хуҗалыгы бүлегенең бер инструкторы (фамилиясен хәтерләмим) райкомнан телефон аша 39 мәсьәлә буенча сводка бирүне таләп иткән. Бу бит, минемчә, Өлкә Комитет бүлегенең эше түгел. Мондый сводкаларны Наркомземнан таләп итәргә кирәк иде. Райком секретарьларының бер киңәшмәсендә иптәш Әлемасов, авыл райкомнарының совет һәм хуҗалык оешмалары җитәкчелеген алмаштыруларын бик урынлы тәнкыйтьләп, киләчәктә ничек эшләргә кирәклек турында ныклы күрсәтмә биргән иде. Авыл райкомнары белән эш иткәндә, Өлкә Комитетның авыл хуҗалыгы бүлегенә дә менә шул күрсәтмәдән чыгып эш итәргә кирәк иде. Ләкин әлегә кадәр бүлек моңа игтибар итмәде.

Авыл районнарына җитәкчелек итү эшендәге мондый кимчелекләргә Өлкә Комитет игтибар итәргә тиеш. Дөрес, район комитетына авыл хуҗалыгының барлык тармакларына җитәкчелек итү эше йөкләнгән, ләкин бу, партия райкомы совет һәм хуҗалык оешмаларының җитәкчелеген алмаштырырга тиеш дигән сүз түгел.

Аннан соң, авыл хуҗалыгы районнарын кадрлар белән тәэмин итү эшендә дә зур җитешсезлекләр барлыкны әйтергә кирәк. Өлкә Комитетта кадрлар бүлегенең авыл хуҗалыгы секторы (иптәш Хайбуллин) моннан ел ярым элек инде безнең райондагы совхозга политбүлек начальнигы җибәрергә вәгъдә иткән иде. Ләкин әле булса да политбүлек начальнигының килгәне юк. Бу бик күп фактларның берсе. Киләчәктә мондый кимчелекләрне бетерергә һәм авыл районнарын кадрлар белән тәэмин итү эшен һәм аларга җитәкчелекне тамырыннан яхшыртырга кирәк.

ВКП(б) нын ТАТАРСТАН ОЕШМАСЫНЫҢ XXI нче ӨЛКӘ КОНФЕРЕНЦИЯСЕ

ВКП(б) ӨЛКӘ КОМИТЕТЫНЫҢ ҺӘМ РЕВИЗИЯ КОМИССИЯСЕНЕҢ ОТЧЕТЛАРЫ БУЕНЧА ФИКЕР АЛЫШУЛАР

Җирле Советларның эшен үзгәртеп коруны тәгалләү өчен

ТАССР Верховный Советы Президиумы Председателе иптәш Динмөхәмәтов речённән

Иптәшләр!

ВКП(б) нын Татарстан Өлкә Комитетының эше турында иптәш Алемасовның отчет доклады партиянең Татарстан оешмасы һәм Өлкә Комитеты эшләгән практик эшне яктырту белән бергә, отчет чорында партия оешмасының эшендә булган зур җитешсезлекләрне дә һәм шулай ук Өлкә Комитетының ялгышларын да ачып сала, партиябезнең XVIII нче съездының тарихи карарларын үтәү буенча Татарстан партия оешмасы һәм Өлкә Комитеты алдына әһәмияте зур булган бурычлар куя.

Мин үземнең чыгышымда хезмәт ияләре депутатларының җирле Советларының эшен үзгәртеп кору турындагы мәсьәләләргә тукталып үтмәкче булам. Хезмәт ияләре депутатларының җирле Советларына үткәрелгән сайлаулар дәүләт власте органнарын һәм дәүләт идарәсе органнарын организацион төзелеш ягыннан Сталин Конституциясе нигезендә үзгәртеп коруны тәгалләделәр. Хәзер җирле Советлар һәм аларның башкарма комитетлары алдында торган бурыч, бу органнарның эшен тамрыннан үзгәртеп корудан гыйбарәт. Җирле Советларның конкрет бурычлары бу советлар турындагы Положениедә күрсәтеләчәк. Ләкин, иптәшләр, бүгенге көн бездән Положение чыкканчы ук инде җирле Советларның эшен үзгәртеп коруны нык таләп итә. Совет дәүләтенең роле һәм бурычлары турында иптәш Сталинның күрсәтмәләре бездә бар. Аннары җирле Советларның функцияләре Сталин Конституциясендә бик ачык билгеләнгән. Хезмәт ияләре депутатларының җирле советларының һәм аларның башкарма комитетларының җитәкчеләре үзләренең практик эшендә иптәш Сталинның күрсәтмәләреннән һәм Конституция белән билгеләнгән бурычлардан чыгып эш итәргә тиешләр.

Хезмәт ияләре депутатларының җирле Советлары дәүләт властеның урыннардагы органнары, эшчеләр сыйнфы диктатурасының иң массовый, хезмәт ияләре белән иң нык элемтәдә булган органнары булып торалар.

Хезмәт ияләре депутатларының җирле Советлары арасында район советы үзәк урын алып тора. Район исә авылда социалистик төзелешнең узловый пункты булып тора. Монда, районда, хуҗалык һәм культура төзелешенең, оборона эшенең һәм башка эшләрнең барлык җепләре бергә кушыла. Шуңа күрә дә партия һәм хөкүмәт район оешмаларын ныгытуга һәм аларга эш шартлары тудыруга зур игтибар бирәләр.

Элек районда дәүләт властеның югары органы булып Советларның район съезды, съездлар арасындагы чорда район башкарма комитетларының пленумнары тора иде. Хәзер районда съезд да, пленум да һәм президиум да юк. Районда дәүләт властеның югары органы булып хезмәт ияләре депутатларының район советы, ә авыл җирләрендә—авыл советлары тора. Район советлары, халыкның санына карап, 25—60 депутаттан, ә авыл советлары 9—25 депутаттан тора.

Район һәм авыл советларының һәм аларның башкарма комитетларының функцияләре ТАССР Конституциясенең 51 нче статьясе белән билгеләнә. 51 нче статьяда күрсәтелгәннәрдән тыш район советының функцияләре башкарма комитетын сайлауга, хезмәт ияләре депутатларының шәһәр, поселкы һәм авыл советларының карарларын һәм бойрыкларын, әгәр алар законга туры килмәсәләр, юкка чыгаруга, башкарма комитетның бүлекләрен һәм даими комиссияләрне төзүгә кайтып калалар. Үзенә йөкләтелгән функцияләрне үтәү теләге белән, район советы карарлар кабул итә һәм бойрыклар бирә. Элекке практикадан аермалы буларак, хәзер район советының башкарма комитеты председателе сессияләрдә председательлек итми. Бу әһәмиятле демократик принцип совет демократизмын тулысынча тормышка ашыру, башкарма комитет эшендәге җитешсезлекләрне большевистик тәнкыйтләү идеясеннән килеп чыга.

Иптәшләр!

Җирле Советларның җитәкчеләре өчен һәм хәтта партиянең урыннардагы оешмаларының җитәкчеләре өчен дә хәзергә кадәр аңлавы читен булган бер мәсьәлә бар. Ул—даими комиссияләрнең бурычлары турындагы мәсьәлә. Бу мәсьәлә буенча төрлечә аңлатулар бар. Берәүләр, даими комиссияләр башкарма комитетлар янында төзеләләр һәм аларның заданиесе буенча эшлиләр дип, ә икенчеләр, даими комиссияләр башкарма комитетларның барлык бүлекләренә беркетеләләр, аларның эшендә булышлык күрсәтәләр, шушы бүлекләрнең эше чикләрендә булышучы органнар булып торалар,—дип аңлаталар. Шулай итеп даими комиссияләрнең функцияләрен аңламау аркасында, күп кенә Советлар үзләренең беренче сессияләрендә ТАССР Конституциясенең таләпләренә, Совет демократизмының гомуми принципларына каршы килә торган карарлар кабул иткәннәр. Мәсәлән, хезмәт ияләре депутатларының Балтач район советының беренче сессиясе даими комиссияләр белән бер үк рәттән план комиссиясе дә төзегән. Ә бит план комиссиясе райсоветның башкарма комитеты янында, бүлекләр белән бер тигез хокукта төзелә. План комиссиясен даими комиссияләр рәтенә кайтарып калдыру Татарстан АССР Конституциясенең 63 статьясенә каршы килә.

Столбище, Биләр, Әгерҗе, Теләче, Зур Тархан, Азнакай һәм Чистай районнары советларының беренче сессияләре даими комиссияләрне райсоветларның башкарма комитетлары янында төзегәннәр. Бу, әлбәттә, даими комиссияләрнең әһәмиятен киметә, аларның бурычларын кечерәйтә.

Даими комиссияләр советларның органнары булып торалар, алар башкарма комитетларыннан бәйле түгелләр. Алар сессияләр каравына кертү өчен мәсьәләләрне җентекләп тикшерәләр һәм аларны алдан хәзерләп куялар.

Заинский район советы сессиясе бюджет комиссиясе председателе итеп РАЙФО мөдирен, авыл хуҗалыгы комиссиясе члены итеп РАЙЗО мөдирен, мәктәпләр буенча комиссия члены итеп РОНО мөдирен сайлаган. Эш шунда ки, даими комиссияләргә тикшерү бурычы йөкләтелә һәм алар сессия каравына кертү өчен теге яки бу мәсьәләләр буенча үзләренең заключениеләрен бирергә тиешләр. Бүлек җитәкчеләренең даими комиссияләр составына хәтта член булып кына сайлануы да бүлекләрнең эшенә бәя биргән вакытта комиссияләрнең эшендә уңайсызлыклар тудыра. Шунлыктан, башкарма комитетларның бүлекләренең җитәкчеләрен даими комиссияләр составына сайлау дөрес түгел.

Даими комиссияләр советларның органы булып торалар, алар башкарма комитеты янында төзелергә һәм башкарма комитетның бүлекләренә беркетелергә тиеш түгелләр.

Иптәшләр!

Мин делегатларның игтибарын советларның даими комиссияләренә шуның өчен юнәлтәм, чөнки алар, комиссияләр, иң массовый форма булып, депутатларны совет эшенә тартуның яңа формасы булып торалар. Партия оешмаларының җитәкчеләре даими комиссияләр турындагы мәсьәләгә большевистик җиддилек белән якын килергә, һәм бу мәсьәләне дөрес хәл итәргә тиешләр.

Дәүләтне идарә итү хәзер культуралылыкны кайчан гына булганга караганда да артыграк таләп итә. Совет дәүләте аппараты, аның барлык работниклары хезмәт ияләренең күп төрле сорауларына җавап бирергә, алар белән культуралы мөгамәлә итә белергә тиешләр. Культурасыз идарә иткән вакытта, совет работниклары идарә итүдә үзләре культурасызлык үрнәкләре күрсәткән вакытта, хезмәт ияләре арасында андый работникларның культуралы эше турында сүзнең булуы да мөмкин түгел. Безнең бу өлкәдәге эшебездә җитешсезлекләр күп әле. Кайбер урыннарда идарә итүдә культурасызлык, кайбер работникларның мөгамәлә итүләрендә тупаслык—җидди җитешсезлекләрнең берсе булып тора.

Идарә итүнең совет системасына чит булган мондый күренешләрне тамрыннан бетерергә кирәк. Советлар һәм аларның работниклары культуралылыкның һәм хезмәт ияләре массасына карата игтибарлылыкның чын үрнәкләрен күрсәтергә тиешләр.

Колхозчылар культуралы һәм таза тормышта яшиләр

Алексеевский районы, Ленин исемендәге колхоз председателе иптәш Максимов речённән

Революциягә кадәр безнең авылда бер мәктәп тә юк иде, крестьяннарнең тормыш-көнкүреш шартлары, патша Россиясендәге барлык хезмәт ияләренеке кебек үк, аяныч иде. Бөек Октябрь Социалистик Революциясеннән соң узган вакыт эчендә безнең авыл танымаслык булып үзгәрде. Хәзер безнең авылда 2 мәктәп бар. 4 кеше югары уку йортларын тәмамлады, 10 кеше техникумда һәм күп кенә балалар тулы булмаган урта мәктәптә укыйлар. Безнең авылда уку өе, клуб бар һәм алар китаплар, газеталар, музыка кораллары белән тәэмин ителгәннәр. Безнең колхозчыларыбызның икмәкләре күп, алар кием-салымга бай.

Безгә бу бәхетле һәм якты тормышны большевиклар партиясе һәм бөек Сталин бирде. Без моның өчен партиябезгә һәм сөекле юлбашчыбыз иптәш Сталинга бурычлы. Колхозчылар моны яхшы беләләр һәм шуңа күрә дә алар колхоз производствосында намуслы рәвештә эшлиләр. Мәсәлән, узган елны безнең колхозда хезмәт көне минимумыннан ким эшләгән бер генә колхозчы да булмады.

Безнең колхоз дәүләт алдындагы йөкләмәләрен һәр елны вакытында үтәп бара. Узган елны ашлык тапшыру, ит, сөт тапшыру планы 100 процент үтәлде һәм 1940 нчы елгы ит тапшыру планы 75 процент үтәлде.

Безнең партоешма да начар эшләми. ВКП(б) ның XVIII нче съездына кадәр партоешмада 4 коммунист бар иде, хәзер оешма 4 кешегә үсте. Алар колхозда иң җаваплы тармакларда: колхоз председателе, терлекчелек фермалары мөдирләре һ. б. булып эшлиләр.

Безнең колхозчылар 1940 нчы елда бөртекле культуралардан кимендә 170 пот уңыш алу бурычын куйдылар һәм без аны үти алырбыз. Чөнки без язгы чәчүгә яхшы хәзерлек белән каршылыйбыз. Яз көне чәчеләчәк мәйдан көздән тулысынча сөреп калдырылды. Авыл хуҗалыгы инвентаре күптән инде яхшы сыйфатлы итеп ремонтланып куелды. Чәчү орлыгы 100 проценты белән чистартылды, кышкы агротехника чаралары артыгы белән үтәлде. Атлар барсы да урта көрлектә. Менә болар, барыннан да бигрәк, безнең колхозчыларыбызның социалистик ярыш, стахановчылык хәрәкәте белән чолганып алынган булулары, аларның колхоз милкенә, хезмәткә намуслы караштa булулары югары уңыш алу буенча алга куелган бурычларның уңышлы хәл кылынуына тулы ышаныч бирәләр.



Партия аппараты үрнәкле эшләргә тиеш

Ленин райкомы секретаре иптәш Ананьев речённән

Партиянең башлангыч оешмалары һәм райкомнар эшендә булган зур кимчелекләр кебек, ВКП(б) Өлкә Комитетының да промышленностька җитәкчелек итүендә



зур җитешсезлекләр бар. Дөрес, кадрлар табуда, аларны җитәкче постларга күтәрүдә барлык оешмаларда да шактый эшләр башкарылды.

Ләкин, монда чыгып сөйләгән иптәшләр әйткәнчә, кадрлар сайлап алу буенча Өлкә Комитеты практикасында кимчелекләр күп әле. Өлкә Комитетының яхшы итеп тикшерелгән, өйрәнелгән кадрлар резервы юк, шуның аркасында теге яки бу эшкә кешеләр кирәк булганда аннан да, моннан да эзләргә керешәләр, кешеләрне эшкә билгеләү турындагы мәсьәләне кайчакта ашыгычлык белән хәл итәргә туры килә. Кешене һәр ягыннан тирәнтен белергә, тикшерергә кирәк. Ләкин тикшерүне сылтау итеп наменклатура раслауны 9 ай буена сузу да яхшы нәрсә түгел.

Хәзер мин икенче мәсьәләгә—промышленностька җитәкчелек итүдәге эш стилен яхшыртуның ничаклы кирәк, ничаклы әһәмиятле булу мәсьәләсенә кагылган кайбер фактларга күчәм. Безнең Татарстан промышленносте зур, без аның белән законлы рәвештә горурланабыз. Өлкә Комитетның промышленностька җитәкчелек итүе дә тулы, аны зур адымнар белән алга этәрергә ярдәм итәрлек булырга тиеш иде. Кызганычка каршы, ул алай түгел әле. Промпредприятиеләрдә Өлкә Комитетының һәм Татсовнаркомның җитәкчеләре бик сирәк булалар.

Москвада эшләгән вактымда иптәш Хрущевның заводларга килгәч ничек эшләве минем хәтеремдә бик нык саклана. Иптәш Хрущев заводка килгәч цехларда була иде, эшчеләр һәм мастерлар белән беседалар үткәрә, партия җыелышларына катнаша иде. Ул политик установкалар бирү белән генә чикләнмичә, технология процесслары белән танышып, кимчелекләрне бетерү өчен практик тәкдимнәр күрсәтә, киңәшләр бирә иде. Безгә дә шулай эшләргә, анардан үрнәк алырга кирәк.

Өлкә Комитетының промышленность мәсьәләләре белән шөгылләнүче работниклары практикасында исә эшкә өстән карaш, „бөтенесен дә беләм“ карашы бик еш очрый. Кайберәүләр заводларга киләләр дә маглүматлар җыярга керешәләр, әле ул кешене, әле бу кешене эшеннән аерып фактлар сорыйлар, цифр чүпләп йөриләр. Район комитеты исә бу турыда белми дә кала. Өлкә Комитетына кайткач безгә телефон белән шалтыраталар да: „бюрога такдимнәр язарга килегез“ диләр. Гадәттә бу бюро алдыннан 2—3 сәгат кенә алдан була. Шушындый кыска вакыт эчендә „төзелгән“ такдимнәрнең сыйфаты нинди булу һәр кем өчен аңлашылса кирәк.

Минемчә, Өлкә Комитеты үзенең аппаратына чын мәгънәсе белән эшлекле, җитәкчелек итә алырлык, түбәнге оешмаларга ярдәм итә алырлык кадрлар тупларга тиеш.

Өлкә Комитеты инструкторларының әнә шулай эшләүләре авылларга баргач икенче формада кабатлана. Миңа авыл райкомнарының берсендә 20 көн эшләп кайтырга туры килде. Шул вакытта мин Өлкә Комитетыннан килгән иптәшләрнең эшенә күз салгаладым. Алар районга килү белән эшкә иң элек ит, сөт хәзерләү мәсьәләләреннән керешәләр, сводкалар белән танышалар. Партиянең эчке эшләре белән исә соңыннан гына, китәргә вакыт җиткәч кенә кызыксына башлыйлар. Мондый хәл совет һәм хуҗалык органнарының аппаратлары кадрлар белән тәэмин ителеп җитмәүдән дә килә. Алар эшен Өлкә Комитеты работниклары үзләре башкарырга мәҗбүр булалар.

Минем такдим: хуҗалык органнары эшен үз өстенә алмаска, бәлки аларга конкрет җитәкчелек итәргә, эштә большевистик стиль булдырырга, җитәкчелекне яхшыртырга, партия эшенең тәмен белеп эшләргә кирәк.

Наркоматлар турында

Татсовнарком председателе урынбасары иптәш Киселев речённән

Иптәш Алемасов үзенең докладында промышленность эшендәге яхшы якларны да һәм шулай ук кимчелекләрне дә тулысынча күрсәтте. Наркоматларның һәм шулай ук Татсовнаркомның эшен бик дөрес итеп тәнкыйтләде.

Без, Татсовнарком җитәкчеләре һәм наркоматлар яхшырак эшли ала идекме? Һич шиксез, эшли ала идек. Ләкин алай булып чыкмады. Ни өчен? Чөнки без наркоматларыбызның бөтен бер организм булып эшләүләренә ирешә алмадык һәм хәзер дә әле күп кенә наркоматларыбыздагы аерым звенолар арасында контакт, аерым секторлар арасында элемтә юк. Кайбер наркоматлар еш кына хәлләрдә оештыру һәм үз предприятиеләренә юнәлеш бирү хезмәтен үтәмиләр, предприятиеләрдәге чын хәлне белмиләр. Мисаль өчен җирле промышленность наркоматын алыйк. Бер вакытны „Красный Путь“ заводының кирәкле материаллар белән, пыяла заводының утын белән җитәрлек дәрәҗәдә тәэмин ителмәгән булуларын наркомат иң соңгы чиратта гына белде. Галантерея фабрикасы буенча булып үткән характерлы бер факт минем әле дә хәтеремдә. Бу фабрика бер вакытны чимал мәсьәләсендә уңайсыз хәлгә калган иде. Тиешле чараларны күргәч, ягни бу юнәлештә Наркомместпромны да һәм шулай ук заводның директорын да яхшылап эшләргә кушкач, чимал шул фабриканың үз территориясендә үк табылды.

Турыдан-туры Татсовнаркомга карый торган предприятиеләрне: төзү материаллары управлениесе заводларын алыйк. Бу управление районнар өчен кирпеч хәзерли. Хәзерге көндә управлениенең кирпеч торырга тиешле 51 сараеннан бары 21 е генә төзек. Арча районындагы дүрт сарайның бары берсе, Ширәмәт районындагы өч сарайның бары берсе төзек. Акташ һәм Баулы районнарындагы кирпеч сарайлары берсе дә хәзер түгел. Кирпеч яндыра торган биналарның да бары сигезе төзек. Ни өчен? Чөнки райсовет башкарма комитетлары җирле промышленность мәсьәләләре белән бөтенләй аз шөгылләнәләр. Совнарком исә бу хәлгә хәзергә кадәр түзеп килде, урыннардан эш таләп итмәде.

Иптәшләр, яхшы һәм бик яхшы итеп эшләү, промышленность, финанс планнарын үтәү, барлык хуҗалык һәм политик кампанияләрне уңышлы итеп башкару өчен бездә мөмкинлекләр бик күп. Тик алардан тулысынча файдалануны оештырырга гына кирәк. Ә моның өчен бездә көч тә, энергия дә һәм теләк тә җитәрлек. Мин ышанам, безнең республикабыз партия җитәкчелегендә, бөек остазыбыз иптәш Сталин җитәкчелегендә киләчәктә, һич шиксез, яңа уңышларга ирешер.

Потребкооперация эшенә партия җитәкчелеге көчәйтелсен

Татсоюзның оештыру бюросы председателе иптәш Осинцев речённән

Потребкооперация эшендә булган җитешсезлекләрне докладчы да һәм чыгып сөйләүче иптәшләр дә бик урынлы һәм дөрес тәнкыйтләделәр. Дөрес, без соңгы вакытта шактый яхшы эшли башладык. Сәүдә обороты планын арттырып үтәдек. Күп кенә район һәм авылларда яңа магазиннар ачтык. Ләкин бу әле сәүдә оешмаларында җитешсезлекләр юк инде дигән сүз түгел. Потребительләргә хезмәт күрсәтү, культуралы совет сәүдәсе өчен көрәш тиешенчә оештырылмаган.

Татсоюз һәм райпотребсоюз аппаратларына кадрлар сайлап алу эше, сәүдә оешмаларына кереп оялаган җуликларга, акча туздыручыларга каршы көрәш әле һаман да начар тора. Татсоюз буенча гына да үткән елны 3 миллион 400 мең сум акча туздыру моның ачык факты булып тора. Юдино районында акча туздыру һәм урлаулар аеруча күп. Бу районда бер ел эчендә 180 мең сум акча туздырганнар. Югары Ослан район кооперацияләре акча туздырулар буенча беренче урынны алып тора.

ВКП(б) нын Юдино, Югары Ослан һәм башка кайбер райкомнары сәүдә оешмаларының эшен яхшыртуга булышлык итү урнына, кайбер тотнаксыз элементларны кооперация оешмаларында җаваплы постларга күтәрү юлына басканнар. Аксубай районында булган факт моны ачык раслый. Бу районның инвалидлар артелендә эшләгән Руковишников дигән кеше артельнең 3 мең сум акчасын туздырган һәм аның эше тикшерү органнарына тапшырылган. ВКП(б) райкомы бу кешене партия җаваплылыгына тарту урнына, аны тагын да җаваплырак эшкә—ашханә мөдире итеп „күтәргән“. Руковишников монда да 6 ай вакыт эчендә ашханәнең 18 мең сум акчасын туздырган.

Югары Ослан райпотребсоюзы председателе Макаровның һәр вакыт эчеп-исреп йөрүе, аппаратны таркату хәленә җиткерүе өчен, акча туздырулар белән көрәшмәве өчен эшеннән алу мәсьәләсе Татсоюз тарафыннан ВКП(б) райкомы алдына берничә тапкыр куелды. Райком аны һәр вакыт яклады. „Ул безнең иң яхшы һәм намуслы работнигыбыз, аны алмаштыру мөмкин түгел“ дигән карарлар чыгарды.

Кадрлар хәзерләү һәм аларны урнаштыру эшенең торышы турында берничә сүз. Райпотребсоюзларда эшләү өчен узган елны Татсоюз аппаратыннан күп кенә иптәшләрне эшкә җибәрдек. Монда да без аерым район оешмалары тарафыннан кайбер тоткарлыкларга очрадык. Мәсәлән, Биектау районы потребсоюзына җибәргән ике иптәшне ВКП(б) райкомы бер кем белән сөйләшмичә икенче эшкә күчерде.

Безнең Татарстанда сәүдә работниклары хәзерләү эше иң тар урыннарның берсе булып тора. Сәүдә работниклары хәзерләү

теләге белән ике урында уку комбинаты оештырылган иде. Хәзер бу эш ничек тора соң? Ачыктан-ачык әйтергә кирәк: бик начар тора. Бөгелмәдәге комбинат эшләми, Казандагы комбинатның да эше шәптән түгел.

ВКП(б) Өлкә Комитетының яңа составы һәм ВКП(б) райкомнары сәүдә оешмаларының эшен яхшыртуга һәр яклап булышлык итәргә тиешләр.

Чит илләрдә

СССР белән Финляндия арасында солых договоры төзелү турында чит ил матбугаты

ЛАТВИЯ

РИГА, 13 март. (ТАСС). Латвиянең җәмагатчелек фикере һәм матбугаты СССР белән Финляндия арасындагы солых договорына кул куюны зур канәгатьләнү белән каршы алдылар һәм бу договорны советның тышкы тынычлык политикасында тагын бер яңа буын дип, Европада тынычлыкны ныгыту эшендә зур әһәмияте булган яңа фактор дип карыйлар. Солых договорына багышланган хәбәрләрнең Москвадан радио буенча бик соң тапшырылуына да карамастан, аны монда зур игтибар белән тыңладылар. Иртә белән иртүк газета киоскылары һәм редакцияләре янында газеталарның договор турындагы хәбәрләр басылган яңа номерларын көтеп халык төркеме җыелды.

Иртәнге газеталарда ук инде беренче битләрендә договор турында тулы материаллар һәм чит илләрдән алынган күп санлы хәбәрләр урнаштырылган иде.

Кечке газеталар барсы да „Правда" газетасының бүгенге номерындагы баш мәкаләсен тулысынча диярлек басып чыгардылар.

„Брива земе" газетасы „Тынычлык файдасына" дигән редакцион мәкаләсендә болай дип яза:

„Үткән төндә Советлар Союзы белән Финляндия арасында солых турында төзелгән договорны без генә түгел, бәлки Балтыйк буендагы барлык дәүләтләр дә зур канәгатьләнү белән каршы ала алалар, чөнки ул Европаның төньяк-көнчыгышында тынычлык урнаштыра.

Хәзер сугыш җир шарының бу почмагыннан яңадан еракка алып ташланды. СССР һәм Финляндия хөкүмәтләре гомуми тынычлык интересларына хезмәт итә торган договор төзеделәр. Бу ике илнең киләчәктә бергәләп эш итүләре дә тынычлыкны ныгытуга юнәлдерелгән булачак. Без тәмам булган солых сөйләшүләренең йомгакларына нак әнә шул караштан чыгып бәя бирергә тиешбез".

„Латвияс карейвис" газетасы солых договоры төзелү турындагы белдерүне „СССР белән Финляндия арасындагы сөйләшүләр ике ил арасында солых договоры төзү белән тәмам булды" дигән исем астында чыгара.

„Яунакас зиняс" газетасы СССР белән Финляндия арасында солых турында договор төзелү турындагы хәбәрне Финляндиянең яңа чикләре күрсәтелгән картасы белән һәм Карелия бугазы турындагы тарихи белешмә белән берлектә басып чыгара. Газета шулай ук СССР белән Финляндия арасында солых төзелү турында күп санда чит ил хәбәрләре дә игълан итә.

ЭСТОНИЯ

ТАЛЛИН, 13 март. (ТАСС). Эстония матбугатында СССР белән Финляндия арасында төзелгән солых договорының тулы тексты игълан ителде. СССР белән Финляндия арасында солых договоры төзелү турындагы хәбәрне Таллинда зур шатлык белән каршы алдылар. Советлар Союзының тынычлыкны яклауга юнәлдерелгән политикасын һәр җирдә дә яхшы дип табалар. Газеталар Совет—Финляндия солых договорының Балтыйк буе районында куркынычсызлыкны һәм тынычлыкны ныгытуын күрсәтеп үтәләр.

ЛИТВА

КАУНАС, 13 март. (ТАСС). Литваның барлык газеталары СССР белән Финляндия республикасы арасында төзелгән солых договорының текстын күренерлек урыннарда басып чыгаралар. Газеталарда Сталин һәм Молотов иптәшләрнең портретлары урнаштырылган.

„XX—й амжиус" газетасы азчылык халыкларның хокукларын саклый торган зирәк Сталинчыл тынычлык политикасының гаять зур уңышларын күрсәтеп үтә. Договорны бөтен илдә зур канәгатьләнү белән каршы алдылар.

ВЕНГРИЯ

БУДАПЕШТ, 13 март. (ТАСС). СССР белән Финляндия арасында солых договоры төзелү Будапештта гаять зур тәэсир калдырды. Договор төзелү турындагы рәсми хәбәрләр төнлә бик соң алынуга да карамастан, иртәнге газеталарның күпчелеге тулы аңлатулар белән чыкты. „Мадьяр шаг" газетасы, договорны Венгриянең котлавын күрсәтеп үтә һәм бу договор „Финляндиянең дәүләт аерымлыгын һәм бәйсезлеген саклауның барлык шартларын тәэмин итә" дип яза.

„Пестер Ллойд" газетасы, договорны гаять зур әһәмиятле вакыйга дип саный һәм Европадагы хәзерге хәлгә договорның яхшы йогынты ясаячагын күрсәтеп үтә.

ШВЕЦИЯ

СТОКГОЛЬМ, 13 март. (ТАСС). Москвада булган сөйләшүләренең нәтиҗәсен Швециядә зур түземсезлек белән көттеләр. Кичә караңгы төшкәч һәм төнлә белән газета витриналары янында соңгы хәбәрләрне көтеп гаять күп халык җыелды. Кичә Стокгольмның бөтен олы яштәге халкы төне буена радиоалгычлар янында Москва радиостанцияләренең тапшыруларын көтеп утырдылар дип әйтү һичбер арттыру булмас. Солых төзелү турындагы хәбәр зур канәгатьләнү һәм шатлык белән каршы алынды.

Швеция гражданнары солых төзелү белән бер-берсен котлыйлар. Бүген иртә белән газета витриналары янында гаять күп халык җыелды. Алар газеталарның хәбәрләре турында сөйләшәләр. Кешеләр сугышның бетүеннән үзләренең канәгатьләнүләрен ачык белдерәләр.

БОЛГАРИЯ

СОФИЯ, 13 март. (ТАСС). Болгария җәмагатчелеге СССР белән Финляндия арасындагы солых сөйләшүләренең барышын гаять зур кызыксыну белән күзәтеп барды. Солых договоры төзелү турында иртә белән иртүк алынган хәбәр зур канәгатьләнү белән каршы алынды. „Слово" газетасы договорның эчтәлеген басып чыгара һәм аны төньяк-көнчыгыш Европада тынычлыкның яңа җиңүе дип характерлый.

КӨНЬЯК СЛАВИЯ

СОФИЯ, 13 март. (ТАСС). Белградтан алынган хәбәрләргә караганда, бүген газеталарның күпчелеге СССР белән Финляндия арасындагы договорга тоташ битләрен багышлыйлар. Договор турындагы хәбәргә политик даирәләрдә тынычлык политикасының гаять зур җиңүе дип бәя бирәләр.

СОВЕТ—ФИНЛЯНДИЯ СОЛЫХ ДОГОВОРЫН КОТЛЫЙЛАР

НЬЮ-ЙОРК, 13 март. (ТАСС). Нью-Йоркта торучы финнәр Совет—Финляндия арасында солых договоры төзелү турындагы хәбәрне зур шатлык белән каршы алдылар.

„Дейли уоркер" газетасы болай дип яза: „Фин халкы солых договорының Ленинградка һәм Фин заливына куркынычсызлыкны тәэмин итүе турында Москвадан бирелгән хәбәрне зур рухлану һәм шатлык белән каршы алды. Совет—Финляндия солых договоры бердәм рәвештә тынычлык һәм куркынычсызлык эшенең гаять зур җиңүе дип карала".

АКШ та финнәр оешмаларыннан берсенең—„Финниш уоркерс холл" оешмасының җитәкчесе „солых договоры Скандинавиядәге барлык илләрнең куркынычсызлыгын ныгытуга ярдәм итәр" дигән.

СОВЕТ—ФИНЛЯНДИЯ СОЛЫХ ДОГОВОРЫ ТУРЫНДА ГЕРМАНИЯ МАТБУГАТЫ

БЕРЛИН, 13 март. (ТАСС). Германиядәге барлык газеталар Советлар Союзы белән Финляндия арасында солых договоры төзелү турындагы хәбәрне күренерлек урыннарда игълан итәләр. „Фелькишер беобахтер", „Дейче алгемейне цейтунг" газеталары һәм башка газеталар договорның текстын, „Правда" газетасы баш мәкаләсенең кыскача эчтәлеген, шулай ук үзләренең чит илләрдәге хәбәрчеләренең махсус мәкаләләрен һәм күп санлы телеграммаларын урнаштыралар. Договор турындагы хәбәрләр „Совет—Финляндия солыхы", „Москва договорының бөтен дөнья күләмендә әһәмияте", „Советлар Союзына каршы сугыш барып чыкмады" һәм башка исемнәр белән чыгарылалар. Күп кенә газеталар Финляндия картасын урнаштыралар.

„Берлинер берзенцейтунг" газетасы болай дип яза:

„Советлар Союзы белән Финляндия арасындагы солых договоры бөтен дөньяның игътибарын үзенә тартты. СССР белән Финляндия конфликтны бетерү һәм төньяк Европада тәмам тынычлык урнаштыру кирәклеге турындагы нәтиҗәгә килделәр. Солых договоры Советлар Союзының яңа территорияләр яулап алырга омтылмаганлыгын, бәлки үз интересларының куркынычсызлыгын тәэмин итәргә генә теләгәнлеген күрсәтә".

„Дейче алгемейне цейтунг" газетасы болай дип яза:

„СССР белән Финляндия арасында яңа чикләр билгеләнде. Моннан элек Балтыйк буе дәүләтләре эшләгән кебек, Финляндия республикасы да Советлар Союзы белән килеште". Ахырдан газета болай дип яза: „Совет—Финляндия конфликты башланганнан бирле үк нейтраль позициядә торган Германия солых төзелүне алкышлый".

Кытай халкы Сун Ят-сенның үлеменә 15 ел тулуны билгеләп үтә

ЧУНЦИН, 13 март. (ТАСС). Кытай халкы Сун Ят-сенның үлеменә 15 ел тулуны үзенең бердәмлеген һәм үзенең бәйсезлеге өчен ахрына кадәр көрәшергә омтылышын көчәйтү белән билгеләп үтә. Чунцин һәм башка шәһәрләрдә урамнарда меңнәрчә лозунглар һәм плакатлар шуны чагылдыралар. Кытай республикасы президенты Линь Сен митингларның берсендә болай диде: „Сун Ят-сен үзенең бөтен тормышын илебезнең азатлыгы өчен көрәшкә бирде. Без дә бәйсезлек өчен көрәшебезне ахрга кадәр дәвам иттерергә тиешбез".

Чунцинда Сун Ят-сенның үлеменә 15 ел тулу көне истәлегенә зур митинг, спорт ярышлары һәм гаскәрләр парады булды. Кич 7 сәгатьтә һәрби совет бинасы алдында күп кеше катнашында зур митинг булды. Трибунада Чан Кай-ши, контроль палата председателе Ю Ю-жень, финанс министре Кун Сян-си, милли оборона верховный советының генеральный секретаре Чжан Цюны һәм башкалар бар иде. Чан Кай-ши речь сөйләде һәм бу речь радио буенча тапшырылды. Чан Кай-ши болай диде: „Илне саклау белән средстволарга экономия ясарга, физкультураны җәелдерергә, сугышчан рухны көчәйтергә һәм армиягә керүне мактаулы эш дип санарга кирәк. Дошманга каршы экономик көрәшне көчәйтергә, аның товарларына бойкот кирәк һәм аңа бер нәрсә дә сатмаска кирәк". Чан Кай-ши учреждениеләрнең һәм заводларның эшен яхшыртырга чакырды. Массовый эшкә кагылып, Чан Кай-ши, митингларда халыкны хәрби белемнәр өйрәнүгә, үзара ярдәм оештырырга акырырга кирәк дип күрсәтте. Ахрында Чан Кай-ши болай диде: „Җиңү безнеке якта, без тагын да кискенрәк булырга тиеш. Дошман безгә зыян китерә алмасын өчен хәзер сыгылырга кирәк. Без үзебезнең идея корылмаларыбызны үткенләтергә һәм җиңү хакына бөтен көчебезне бирергә тиешбез".

КЫТАЙДА СУГЫШ ХӘРӘКӘТЛӘРЕ

КӨНЬЯК КЫТАЙДА. Гуанси провинциясенең көньяк өлешендә артиллерия хәзерлегеннән соң кытай гаскәрләре 11 нче мартта японнарның Наньниннан 10 километр төньяк-көнчыгыштагы булган позицияләрен алдылар.

Гуандун провинциясендә Чаочжоу—Сватоу районында сугыш хәрәкәтләре дәвам итә. Монда японнар һөҗүм ясарга маташалар.

ТӨНЬЯК КЫТАЙДА. Шаньси провинциясенең көньяк-көнбатыш өлешендә японнар гаскәрләре Датун—Пучжоу тимер юлының көньяк тармагы буендагы күп кенә пунктларны алдылар.

Хэнань провинциясенең төньяк-көнбатыш өлешендә япон гаскәрләре 10 нчы мартта Хуанхэ елгасының төньяк ярында, Лояньнан төньяк-көнчыгыштагы районда кытай позицияләренә уңышсыз атака ясадылар.

ҮЗӘК КЫТАЙДА. Үзәк Кытайдагы фронттагы хәл турында хәбәрләр юк.

Татарстан хезмәт ияләре Сталинчыл тынычлык политикасының яңа җиңүен кайнар рәвештә котлыйлар

(ТатТАСС һәм үз хәбәрчеләребездән)

Биләр районында

СССР белән Финляндия республикасы арасында солых договоры төзелүгә багышлап, Биләр районы колхозларында һәм учреждениеләрендә зур митинглар булды. Сталин исемендәге колхозда булган митингта 274 кеше катнашты. Колхозчы иптәш Гыйлаҗев болай дип белдерде:

— Мин, бөек Ватаныбызның барлык хезмәт ияләре шикелле үк, Сталинчыл тынычлык политикасының яңа җиңүен котлыйм һәм илебезнең төньяк-көнбатыш чикләре куркынычсызлыгын тәэмин итүче, бигрәк тә пролетар революциясенең бишеге булган Ленин шәһәренең куркынычсызлыгын тәэмин итүче солых договорын шатлык белән каршылыйм. Безнең даньлыклы Кызыл Армиябез бөтен дөньяга СССР ның көчен һәм куәтен тагын бер тапкыр күрсәтте, бөтен совет халкы тарафыннан үзе алдына куелган бурычларны үтәп, батырлык һәм геройлык күрсәтте.

Митингта бер тавыштан кабул ителгән резолюциядә:

— Совет хөкүмәтенең тынычлык политикасын котлыйбыз, кадерле юлбашчыбыз иптәш Сталинның, Совет хөкүмәте башлыгы иптәш Молотовның озак һәм озак еллар буе исән-сау булуын телибез,—диелә.

Биектау районында

Совет Союзы белән Финляндия арасында солых договоры төзелү турындагы хәбәрне Биектау районы хезмәт ияләре зур шатлык белән каршыладылар. Район үзәгендә булган митингта җыелган 400 кеше Совет хөкүмәтенең тынычлык политикасының яңа җиңүен бердәм рәвештә котладылар.

Митингта сөйләгән иптәш Семенов болай диде:

— Даньлыклы Кызыл Армиянең җиңүләре безне горурландыра. Безнең хөкүмәтебез Финляндия белән солых договоры төзеп, үзенең тынычлык политикасын бөтен дөньяга тагын бер тапкыр күрсәтте.

Кукмара районында

Кукмара районында Культура йортында 13 нче мартта Кукмара поселкасы хезмәт ияләренең митингысы булды. Анда 650 кеше катнашты. Кукмара хезмәт ияләре бердәм рәвештә кабул ителгән резолюциядә Сталинчыл тынычлык политикасын—183 миллионлы совет халкы политикасын шатлык белән котлыйлар.

Резолюциядә:

— Без Советлар Союзының оборона куәтен тагын да ныгытырга сүз бирәбез,—диелә.

„Кызыл Тукучы" фабрикасында һәм районның колхозларында да зур митинглар булды.

Апас районында

Апас районының колхозчылары һәм хезмәткәрләре СССР белән Финляндия арасында солых договоры төзелү турында радиотапшыруны тирән канәгатьләнү белән тыңладылар. Барлык учреждениеләрдә коллектив рәвештә радио тыңлаулар оештырылды. Агитатор коммунист иптәш Биккулов радиотапшырудан соң колхоз мәктәбендә беседа алып барды.

13 нче мартта Культура йортында митинг булды. Анда „Кызыл армеец" колхозының 300 члены катнашты. Митинг Сталинчыл тынычлык политикасын котлап, бердәм рәвештә резолюция кабул итте.

Чепья районында

Чепья районы хезмәт ияләре Советлар Союзы белән Финляндия республикасы арасында төзелгән солых договорын зур күтәренкелек белән каршыладылар. 13 нче мартта Чепьяда зур митинг булды.

Митингта сөйләгән ораторлар Совет хөкүмәтенең тынычлык өчен көрәштә тагын бер зур җиңүгә ирешкәнлеген, Кызыл Армиянең чиксез геройлыгын күрсәтеп үттеләр.

Митинг көчле кул чабулар астында бердәм резолюция кабул итте.

Чистай районында

СССР белән Финляндия республикасы арасында солых договоры төзелү уңае белән Чистай шәһәренең судноларга ремонт ясау заводы цехларында митинглар булды. Электромонтаж цехы стахановчысы иптәш Макеев үзенең чыгышында болай ди:

— СССР белән Финляндия республикасы арасында солых договоры төзелү—СССР ның сугыш теләмәвен, хезмәт ияләренең тыныч яшәве өчен өзлексез көрәш алып баруын тагын бер кат раслый торган бөек документ. Без бөек Ватаныбызның оборона куәтен барлык чаралар белән ныгытырга, производствода хезмәт житештерүчәнлеген тагын да күтәрергә тиешбез.

— Безнең сөекле хөкүмәтебез,—ди райсовет депутаты иптәш Васина,—бер вакытта да сугыш теләмәде һәм теләми. Ә инде сугыш уты кабызучылар безнең илебезгә һөҗүм итәләр икән, алар һәр вакытта икеләтәударга очраячаклар.

Юдино районында

13 нче мартта Юдин исемендәге клубта Юдино тимер юл узелы эшчеләренең һәм хезмәткәрләренең митингысы булды. Митингта 800 дән артык кеше катнашты. Катнашучылар Совет хөкүмәтенең тынычлык политикасының яңа җиңүе турындагы хәбәрне зур кызыксыну белән тыңладылар. Паровоз бүлеге начальнигы иптәш Губа болай диде:

— Англия—Франция империалистлары Финляндияне Советлар Союзына каршы котырттылар. Ләкин аларның планнары челпәрәмә килеп җимерелде. Совет халкы, большевиклар партиясе җитәкчелегендә, бөек Сталин җитәкчелегендә, үзенең какшамас бердәмлеген, империалистик ерткычларның теләсә нинди омтылышларын кире кайтарырга һәм үз Ватанының чикләре куркынычсызлыгын тәэмин итәргә сәләтле икәнлеген күрсәтте.

Кабул ителгән резолюциядә болай әйтелә:

— „Без, Юдино узелы тимер юлчылары, Совет хөкүмәтенең зирәк политикасын тирән канәгатьләнү белән котлыйбыз. Бу политика безнең төньяк-көнбатыш чикләребезнең куркынычсызлыгын һәм бигрәк тә Октябрь революциясенең бишеге булган Ленин шәһәренең куркынычсызлыгын тәэмин итте".

Баулы районында

13 нче мартта иртә белән иртүк радио СССР белән Финляндия арасында солых договоры төзелү турында шатлыклы хәбәрне китерде. Сталинчыл тынычлык политикасының яңа җиңүе белән кешеләр бер-берсен котладылар.

Хезмәттән соң Баулы клубында эшчеләрнең, хезмәткәрләрнең һәм „Йолдыз" колхозы членнарының митингысы булды. Анда 300 кеше катнашты.

Солых договоры төзелү турындагы хәбәрне тыңлаганнан соң 65 яшьлек колхозчы Газый иптәш Мусин түбәндәгечә белдерде:

— Безнең изге чикләребезнең һәм Ленин шәһәренең куркынычсызлыгын тәэмин итү өчен Кызыл Армия тарафыннан алып барылган көрәшнең бөтен чорында без, колхозчылар, данлыклы Кызыл Армиянең җиңүенә нык рәвештә ышандык. Солых договоры төзүне без кайнар рәвештә котлыйбыз. СССР үзенең куәтен һәм көчен тагын бер тапкыр күрсәтте. Ә Кызыл Армиянең батыр сугышчылары партияле һәм партиясез большевиклар ала алмаслык крепостьларның юк икәнлеген тагын бер тапкыр күрсәттеләр.

СССР белән Финляндия арасында солых договоры төзелүгә багышланган митинглар шулай ук „Урал", „Кызыл армеец" һәм башка колхозларда да булды.

Бондюг районында

Советлар Союзы белән Финляндия республикасы арасында солых договоры төзелү турындагы хәбәрне Бондюг заводының эшчеләре, хезмәткәрләре һәм инженер-техник работниклары зур күтәренкелек белән каршыладылар. Күп кенә цехларның кызыл почмакларында эшчеләр радио тапшыруны икешәр тапкыр тыңладылар.

13 нче мартта 16 сәгатьтә завод күләмендә зур митинг булды. Митингта сөйләгән эшчеләр хөкүмәтебезнең Сталинчыл политикасын кайнар рәвештә котладылар.

Митингта завод эшчесе Калягин:

— Советлар Союзы белән Финляндия арасында төзелгән солых договоры Сталинчыл тынычлык политикасының яңа гүзәл җиңүе булып тора,—дип белдерде.

Митингта бердәм рәвештә резолюция кабул ителде.

ВКП(б) ның Татарстан оешмасының XXI нче өлкә конференциясе хөрмәтенә 12 нче мартта мотоклуб мотоциклларда ярыш үткәрде.

РӘСЕМДӘ: Ярышта җиңеп чыгучылардан, „Учитель" спорт җәмгыяте членнары Б. Благодаров һәм Лапшев иптәшләр противогазларда.

Л. Попов фотосы.

МИНЗӘЛӘ КӨТЕПХАНӘСЕ

Минзәлә шәһәренең үзәк көтепханәсендә 14.315 данә китап исәпләнә. Анда Маркс, Энгельс, Ленин, Сталин әсәрләре, шулай ук рус һәм татар классик язучыларының әсәрләре бар. Көтепханәгә 30 төрле газета-журнал алына.

Районның хезмәт ияләре көтепханәгә зур кызыксыну белән йөриләр. Һәр көн уртача 150 дән артык укучы була. Көтепханә янында радиосөючеләр, әдәбият һәм кыллы оркестр түгәрәкләре эшләп килә. Халыкара хәл һәм башка темаларда еш кына лекцияләр үткәрелә.

Минзәләнең балалар көтепханәсе дә яхшы гына эшләп килә. Бу культура учагына үткән ел 2.500 гә якын бала йөргән.

Г. Бикмул.

Җаваплы редактор
Һ. АБДРАХМАНОВ.
Ответ. редактор Х. АБДРАХМАНОВ.

Клублар, югары уку йортлары, мәктәпләр, фәнни-җәмагат оешмалары һәм учреждениеләр игътибарына!

„Союзкинопрокат" ның Татарстан бүлеге
күп санда фәнни, фәнни-популяр һәм укыту-техник фильмнәрдән
киң пленкалы тавышлы һәм тавышсыз
ЯҢА ФИЛЬМНӘР АЛДЫ ҺӘМ АЛАРНЫ БАРЛЫК
ОЕШМАЛАРГА ПРОКАТКА БИРӘ

КИҢ ПЛЕНКАЛЫ ТАВЫШЛЫ ФИЛЬМНӘР:
1. Йөрәк ритмының бозылуы.
2. Афты клапаннарының житешсезлеге.
3. Стратосферага.
4. Бөҗәкләр дөньясында.
5. Диңгез тавышы.
6. Дәүләт Третьяков галлереясе.
7. Эрмитаж.
8. Советлар илендә сәламәтлек саклау эше.
9. Сугышта кулланыла торган агулау әйберләре.
10. Һава почтасы.
11. Амалфила.
12. Астрахань слипы.
13. Диңгез төпләрендә.
14. Очырткыч.
15. Җитеннең югары уңышы өчен.
16. Божралы ефәкче.
17. Диңгез төбе кешеләре.
18. Манго-ней (Амур кешесе).
19. Амазонка кырмыска.
20. Үрмәкүчләр.
21. Пулково.
22. Туган кан.
23. Үсемлекләрнең үсүе.
24. „Бодо" телеграф аппараты.
25. Твинвейр.
26. Авыруны өйдә тәрбияләү.
27. Электромагнит.
28. Сабан бодаена стахановча агротехника.

ТАВЫШСЫЗ ФИЛЬМНӘР:
1. Битте пластик операцияләр.
2. Хирургия сестрасының эше.
3. Колхозда санитария чаралары.
4. Трахома.
5. Инфекцион бүлектә авыру балаларны тәрбияләү.
6. Имчәк баласын тәрбияләү.
7. Агулар һәм аларның организмга тәэсире.
8. Ясалма бугаз.

Фильмнәрне прокатка алу өчен, түбәндәге адрес буенча, бүлекнең конторасына килергә: Казан, Нариманов урамы, 66. Телефон 2—05.
451—1

Центроэлектромонтаж трестының Казан конторасына, Казанда һәм башка урыннарга китеп эшләү өчен, ирләрдән һәм хатын-кызлардан — БАРЛЫК РАЗРЯД ЭЛЕКТРОМОНТЕРЛАР, ЭЛЕКТРОСЛЕСАРЬЛАР, ПРОИЗВОДСТВОЧЫ БУХГАЛТЕР һәм берәр эш буенча квалификация алырга теләгән ГАДИ ЭШЧЕЛӘР кирәк. Кирәк кешеләргә тулай торакта урын бирелә. Контораның кадрлар бүлегенә килергә. Казан, Банк урамы, 13.
408—5—3

Казан 2 нче төзәтү-хезмәт колониясенә БУХГАЛТЕРЛАР, ӨЛКӘН БУХГАЛТЕРЛАР, КАРТОТЕКАЧЫЛАР, ХИСАПЧЫЛАР, ЖИТЕШТЕРҮ БҮЛЕГЕ РАБОТНИКЛАРЫ, ИНЖЕНЕР-ТЕХНОЛОГЛАР ҺӘМ АГАЧ МАТЕРИАЛЛАР СКЛАДЫ ӨЧЕН МӨДИР кирәк. Хезмәт хакы килешү буенча. Кызыл Армия бистәсе, 1 нче маршрут трамвайларының Петров паркы янындагы тукталы. Телефон № 19—22.
345—3—1

ДӘҮЛӘТ ЦИРКЫ
Бүген, 15 нче мартта, данлыклы
ЗОЛЛО ТИМЕР ЮЛЫ
300 хайван һәм кошлар катнаша һәм башка күп номерлар.
РСФСР ның атказанган артисты орденлы
М. ЗОЛЛОның
соңгы гастрольләренә билетлар сатыла.
Уен кич 8 дә башлана.
Касса һәр көн көндез 11 сәгатьтән 3 кә һәм кич 5 тән 9 га кадәр ачык.

ГОСМУЗПРОКАТ
рояль һәм пианинолар сатып ала һәм сата.
Клавишлы музыка коралларын көйләү, ремонтлау, упаковкалау, күчерү һәм аларга экспертиза эшләре үтә.
Гитара, мандолина, скрипка һәм башка төрле щипной музыка коралларын ремонтка ала.
Госмузпрокат Казанда һәм Татарстан республикасы районнарында прокатка музыка кораллары алучы учреждениеләргә, оешмаларга һәм гражданнарга белдерә: прокатка алынган музыка коралы өчен тиешле прокат түләве буенча булган бурычлар 3 көн срок эчендә түләнмәсә,—прокатка бирелгән музыка кораллары алыначак. Контораның адресы: Казан, Пионер урамы, 10 (Бауман урамы ягыннан керелә). Телефон 6—73. Контора иртән 8 сәгатьтән көндезге 4 кә кадәр эшли.
326—2—1

ТАТАРСТАН АССР ОСОАВИАХИМ ҮЗӘК СОВЕТЫНЫҢ
АВТО МӘКТӘБЕ
производстводан аерып укытып III нче класс шоферлар хәзерләү һәм III нче класс шоферлардан II нче класс шоферлар хәзерләү курсларына
УКУЧЫЛАР АЛА
Укучылар учреждениеләрдән һәм предприятиеләрдән бирелгән командировкалар белән алыналар. Казан, Профсоюз урамы 10/14. Телефон 25—43.
389—3—1

ТАТАР ДӘҮЛӘТ ОПЕРА ТЕАТРЫ
Татар Дәүләт Академия театры бинасында.
16 нчы мартта
ИРЕК
Талон 88.
Кич 7 сәгат 30 минутта башлана.
Коллектив рәвештә килү өчен 29—04 телефоны буенча заявкалар алына.

Галиәсгар Камал исемендәге
Татар Дәүләт Академия театры
17 нче мартта
Булак арты „республикасы"
Талоннар белән кертелми.
Спектакль кич 7 сәгат 30 минутта башлана.
Касса һәр көн көндез 11 сәгатьтән 2 гә һәм кич 5 сәгатьтән 9 га кадәр ачык. ТДАТ.

ЗУР ДРАМА ТЕАТРЫ
Бүген, 15 нче мартта
МАСКАРАД
Талоннар белән кертелми.
Спектакльләр кич 7 сәгат 30 минутта башлана.
Билетлар көндез 11 сәгат 30 минуттан 2 гә һәм кич 5 сәгатьтән 7 сәгат 30 минутка кадәр кассада сатыла.

„ЭЛЕКТРО" 12, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да.	Тавышлы, художестволы, яңа фильм ТАШЛАНДЫК
„УНИОН" 12, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да.	ПРЕМЬЕРА ИСТРЕБИТЕЛЬЛӘР
„КЫЗЫЛ ЙОЛДЫЗ" 6, 8 һәм 10 да	ДОКТОР КАЛЮЖНЫЙ
„ЧАТКЫ" 6, 8, 9-30 да.	ПРИДАНСЫЗ КЫЗ
„ПИОНЕР" 11, 1, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да.	ШӘХСИ ЭШ Көндез 1 сәгатьтә мәктәпкә кадәр яштәге балалар өчен сеанс.
„Колхозник" 6, 8 һәм 10 да.	ПАТРИОТ
„РОТ-ФРОНТ" 6, 8, 10 да.	ХӘЗИНӘЛӘР АТАВЫ
КУЛЬТУРА САРАЕ 5, 7, 9 да.	ЯШӘРГӘ

УПОЛН. ГЛАВЛИТА ТАССР. № А — 274 ТИПОГРАФИЯ ИМЕНИ АЛЕКСАНДРОВА. ДОМ ПЕЧАТИ 1940 ГОД. ЗАКАЗ № 1010.